ГЛАВА БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
Олы МемиАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.10.2022 с. Большие Меми № 2

Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004нче елның 28нче июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан районының Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылы халкының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 2022 елның 10 ноябрендә 10 сәгатькә билгеләргә.
2. Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылы халкының үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 2022 елның 10 ноябрендә 11.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылы халкының үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын 2022 елның 10 ноябрендә 15.00 сәгатькә билгеләргә.
4. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
1 этап: Олы Меми авылы, Заречная урамы, Исаевка урамында яшәүчеләр
2 этап: Олы Меми авылы, Яшьләр урамында яшәүчеләр
3 этап: Олы Меми авылы, Гаврилов Я.А., Үзәк урамында яшәүчеләр
5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«2022 елда Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Олы Меми авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә рөхсәтегез бармы:
- Олы Меми авылында өлешчә зират коймасы, һәйкәл коймасын ясау

«ӘЙЕ» «ЮК»

6. Гражданнар җыеннарын уздырырга:
1 этап: Олы Меми авылы, Заречная урамы буенча 15 нче йорт янында
2 этап: Олы Меми авылы, Яшьләр урамы буенча 18 нче йорт янында
3 этап: Олы Меми авылы, Гаврилов Я.А. урамы буенча 45 нче йорт янында

7. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районының
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина